РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2023 елның 13 марты** **№37**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемаларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. «Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәр тибындагы бистәсе территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 29 сентябрендәге 33 номерлы Кукмара бистәсе башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны шәһәр территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **Р.Р. Хәйруллин**

Исполнительный комитет города Кукмор
ИНН 1623008296
Кукмара шәһәре башкарма комитеты

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның «13» мартындагы 37 номерлы карарына 1 нче кушымта

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/б | Стационар булмаган сәүдә объектларының исеме һәм урнашу урыны | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектлары төре | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кукмара шәһәре, Ворошилов ур., («Кукмара РҮХ» тукталышы артында) | газета, журналлар, камыр ризыклары, азык-төлек | павильон | даими |
| 2 | Кукмара шәһәре, Нур Баян ур., 42 йорт (йорт каршындагы мәйдан) | азык-төлек продуктлары, көндәлек таләп ителә торган товарлар | автолавка, автокибет Лавка | даими |
| 3 | Кукмара шәһәре, Ленин урамы (автозаправка белән «Добреев» сәүдә йорты арасындагы территория ) | азык-төлек продуктлары, көндәлек таләп ителә торган товарлар | автолавка, автокибет, лавка | даими |
| 4 | Кукмара шәһәре, Комсомоля мәйданы | азык-төлек продуктлары, көндәлек таләп ителә торган товарлар | автолавка, автокибет лавка | бәйрәм чаралары, мәктәп ярминкәләре вакытында, җәйге чорда |
| 5 | Кукмара шәһәре, Атлас Булатов исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркы (Хәтер паркы) | азык-төлек продуктлары, көндәлек таләп ителә торган товарлар | автолавка, автокибет, лавка | даими |
| 6 | Кукмара шәһәре, ТАССРның 100 еллыгы скверы | азык-төлек продуктлары, көндәлек таләп ителә торган товарлар | автолавка, автокибет, лавка | даими |
| 7 | Кукмара шәһәре, Ворошилов ур., Бертуган Комаровларның Кунак йорты | азык-төлек продуктлары, көндәлек таләп ителә торган товарлар | павильон, автолавка, автокибет, лавка | даими |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Кукмара шәһәре, Нурминкә елгасы яр буе | азык-төлек продуктлары, көндәлек таләп ителә торган товарлар | павильон, автолавка, автокибет, лавка | даими |
| 9 | Кукмара шәһәре, Ленин урамындагы 1 нче бина каршындагы территория | азык-төлек продуктлары, көндәлек таләп ителә торган товарлар | павильон, автолавка, автокибет, лавка | даими |
| 10 | Кукмара шәһәре, Вахитов урамы, «Каенкай» МБМББУ каршындагы территория | азык-төлек продуктлары | автолавка, автокибет | даими |
| 11 | Кукмара шәһәре, Ленин бакчасы скверы (Почта урамы ягыннан тукталыш) | азык-төлек продуктлары | автолавка, автокибет | даими |